конференции (Казань, 26–28 апреля 2018 г.). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. - С.73-79

2. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р.Галиуллина . – Казан: ТӘҺСИ, 2017. – Т. III. 1 кис. – 536 б.

3. Әхмәдгалиева Г.Г. Интернет басмаларда сөйләм стиле // https://kpfu.ru/staff_files/F1873605848/Ahmadgalieva_G.G._Internet_basmalarda_sojlem_stile_Barda.pdf

***А. И.Нигъмәтҗанова***
студент
Казанский (Приволжский) федеральный университет
*г. Казань, Россия*
© А. И.Нигъмәтҗанова
***Р.Л.Зәйни***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
*г. Казань, Россия*
© Р.Л.Зәйни

# ТНВ – ЯҢА ГАСЫР» ТЕЛЕКАНАЛЫНДА ТРЭВЕЛ-ЖУРНАЛИСТИКА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (ЮЛЧЫ» ТАПШЫРУЫ МИСАЛЫНДА»)

*Аннотация. В статье рассматриваются различные аспекты малоизученного направления в журналистике – трэвел-журнализм. Тема посвящена изучению телепередачи Путник» (Юлчы») на телеканале ТНВ. Методология исследования основана на понимании миссии СМИ как важного средства популяризации знаний о других странах и народах, их роли в межнациональном общении. Статья основное внимание уделяет сегодняшним проблемам трэвел-журналистики в контексте актуальных вызовов глобализации. Рассматриваются особенности программы, показаны его преимущества и недостатки, дан глубинный анализ работе ведущего. Специфические черты трэвел-журналистики на телевидении, выявленные в работе, могут стать полезной информацией для путешествующих журналистов и студентов высших учебных заведений.*

*Ключевые слова: трэвел-журналистика, телепередача, трэвел-текст, журналистика путешествий, путешествия, туризм, пресс-тур*

*Abstract. The article examines several aspects of the understudied genre of journalism – travel journalism. The topic is devoted to the study of the TV program The Traveler» (Yulchy») on the Broadcasting Company The New Age channel (TNV). The research methodology is based on an understanding of the mission of the media as an important means of popularizing knowledge about other countries and peoples, their role in international communication. The article focuses on today's issues of travel journalism in the context of current challenges of globalization. The features of the program are considered, its advantages and disadvantages are shown, an in-depth analysis of the work of the leader is given. The specific features of travel journalism on television, identified in the work, can be useful information for traveling journalists and students of higher educational institutions.*

*Keywords: travel journalism, travel, tourism, tr*avelogue, genres of journalism, press-trip, travel journalism studies.

Татар телеканалларында чит җирләрне һәм шунда яшәүче кешеләрне күрсәтергә омтылышлар булса да, сәяхәт турында тапшырулар төшерелмәде. Моңарчы, телевидениедә татар милләте, башка җирләрдә сибелеп яшәүче татарларның тормышын яктырту максаты куелды. Сәяхәтләр турында тапшыруларны икенче төрле трэвел-журналистика» сүзе [3:150] белән атап йөртәләр. Ләкин ул рәсми төшенчә түгел, бу очракта инглиз теленнән күчкән алынма сүз генә (travel» – сәяхәт дигәнне аңлата) кулланыла. Термин журналистиканың әлеге тармагында барган барлык үзгәрешләргә (блоглар, гражданлык журналистикасы), хәзерге көн, заман таләпләренә туры килә дип саныйбыз. Акрынлап, ул халык теленә кереп бара. Трэвел-журналистика исә аудиториягә сәяхәт итү, тарих, география, сәнгать, туризм, әхлак, фәлсәфә, бюджет, гастрономия турында мәгълүмат җиткерә. Төп максаты чит илләр, башка мәдәният белән танышу, яңа җирләрне күрсәтүгә омтылу.

Әлбәттә, төбәк телеканаллары мондый типтагы тапшырулар төшергәндә, берничә кыенлык белән очраша [2:100]: тапшыруны кем карый, нәрсә төшерергә һәм финанс мәсьәләсен ничек хәл итәргә. Иганәчеләр табуы авыр. Гәрчә, акчалата ярдәм итүчеләр табылса да, проект үзен акларга тиеш, ягъни караучылар санының

күп булуы зарур. Ләкин Интернет барлыкка килү белән телевидение үз тамашачыларын югалта башлады. Моңа да карамастан, туризм темасына багышланган тапшырулар төшерелә. Яңа Гасыр» каналында да яңа юнәлешне үзләштерә башладылар. Юлчы» тапшыруының беренче сериясе 2018 елның 29 сентябрендә чыкты. Алып баручысы – Альберт Шакиров. Биредә юл мотивы беренче урында. Ул татарның тарихы белән бәйле истәлекле урыннар, табигать һәйкәлләре, туристик үзәкләр буйлап сәяхәт итә.

Тапшыруның концепциясе буенча, алып баручы Казаннан теге яки бу кызыклы, истәлекле урыннарга ничек барырга, милли ашсулар нәрсәдән гыйбарәт, кайда тукталырга һәм күпме акча алырга, нәрсәләр карарга икәнлеге турында сөйләргә тиеш була. Ләкин төшерү барышында әлеге идеяләр үзгәрә, һәм тапшыруда тарих алгы планга куела. Алга таба вәзгыятьне үзгәртергә ышандыралар.

Юлчы» тапшыруында Уфа, Оренбург, Башкортстанның авыл һәм шәһәрләре, Татарстанның Азнакай районындагы Тымытык авылы гына күрсәтелде. Юлчы» проекты телевизор экраннарында очраклы гына барлыкка килмәде. ТНВ – Яңа Гасыр» каналында төрле темаларга тапшыру әзерләүче яңа сәләтләрне ачыклау максатыннан уздырылган Талант» конкурсында Альберт Шакиров җиңүче дип табылды. Конкурсантлар үз тапшыруларын каналда трансляцияләү хокукына көч сынашты.

Юлчы» проекты телевидениенең кануннарына таянып төшерелгән. Ләкин машина сөртеп йөрү, дрон артыннан йөгерү, алып баручының рус сүзләрен кулланган очракта, татарча әйткәндә» дигән үзенчәлекле гыйбарәсе дә халыкка якынлашу кебек тоела. Әлеге мизгелләр проектны влогларга охшата. Ләкин серия дәвамында гадилеккә, табигыйлыкка йөз тоту артык күп очрамый, документальлек беренче урында.

Юлчы» – татар халкы тарихы белән бәйле истәлекле урыннар, табигать һәйкәлләре, туризм үзәкләре буйлап сәяхәт итү турындагы тапшыру. 14 чыгарылышка исәпләнгән. Хронометражы 24 минут. Башлыча, мәгърифәтчел характерда. Туризм һәм сәяхәтләр турындагы татар телендәге беренче тапшыруның көчле якларын билгеләргә мөмкин:

- Һәрдаим динамика булдырырга тырышу,
- Документальлеккә омтылу, мөмкин кадәр күбрәк фактлар әйтү,

- Бай мәгълүмат, моның өчен тарихчылар, төрле темаларны яхшы белгән белгечләргә мөрәҗәгать итәләр,
- Алып баручының профессиональлеге, төпле белемгә ия булуы.

Әмма тапшыруга берничә үзгәреш кертү дә кирәк дип саныйбыз:

- **Бирелеш формасын җиңеләйтү** – Юлчы» форматны җиңеләйтергә, катгый телевизион кануннардан читләшергә тели. Әйтергә кирәк, Талант» конкурсына килгән эшләрнең күбесе блогерлык форматында була, ул, әлбәттә, телевидениегә туры килеп бетми. Әмма Юлчы»ны төшергәндә дә бераз Интернет, гражданлык журналистикасына якынайтырга омтылалар. Хис-тойгыларны күрсәтергә тырышалар, табигыйлык өстенлек итүен телиләр. Әмма артык җитдилек сакланып калган.

- **Инфотейнтмент алымын куллану** – ягъни тарихи корылмалар турында коры мәгълүмат һәм фактлар гына булырга тиеш түгел, хәрәкәтчәнлек һәм табигыйлык күзәтелсен. Төрле якларга хас бәйрәмнәр, нииндидер йолаларны чагылдырырга һәм Юлчы» төркеменә шуларда катнашырга була. Кунакханәләр бармы, шәһәр төзекме, шушы мәсьәләләргә басым ясарга кирәк. Авыл туризмы, этник маршрутлар ни дәрәҗәдә гамәлгә ашырылуын да күрсәтүләре урынлы булыр иде дип саныйбыз. Бу тамашачының да хәбәрдарлыгын арттырыр, шул ук вакытта, яхшы рейтингларны да саклап калырга ярдәм итәр.

-**Тематиканы тирәнәйтү** (Трэвел-журналистиканың төрле юнәлешләрен чагылдыру) – тапшыруда яу кадрлары, тарихи фильмардан өзек, карталар бар, алып баручы хәтта шигырь юлларыннан өзекләр дә укый. Ләкин трэвел-журналистика тарихтан гына гыйбарәт түгел. Аудиториягә сәяхәт итү, география, сәнгать, туризм, әхлак, фәлсәфә, бюджет, гастрономия турында да мәгълүмат җиткерелергә тиеш. Бу эчке туризмны да киңәйтергә ярдәм итә дип саныйбыз.

-**Төшерү мизгелләрен яктырту** – төшерү төркеме кайда куна, буш вакытын ничек үткәрә, машинада сәяхәт итүнең уңай һәм тискәре яклары нинди – шул темаларны да күтәрергә кирәк. Бу – тапшыруны мәгълүматый яктан тагын да баетыр дип уйлыйбыз. Сәяхәтнең дүртенче көне [6] – 3 ноябрь чыгарылышында күрсәтелә. Башы шулай ук юл мизгелләреннән гыйбарәт. *Түбәндә кымыз*

*эчеп яттык, табигый, тәмле»* дип кереш сүзен башлап җибәрә алып баручы. Вакытны Татарстанныкы белән чагыштыра. Дрон җайланмасы белән төшерәләр, аны төрлечә кыландырып карыйлар, шул хакта да әйтә. *Безнең дураклыклар»*дип атый. Бер яктан караганда, мәгърифәтчел тапшыруда мондый сүзләрне куллану урынлы түгел, әмма бу табигыйлек, гадилеккә ишарә дип кабул итәргә мөмкин. Юлчы»ның форматына туры килеп бара. Алып баручы рульдә барганда да текстлар сөйли, тамашачыга якын дустына эндәшкән кебек мөрәҗәгать итә, бу шулай ук җиңеллеккә омтылуны аңларга мөмкинлек бирә.

Җирле халык, тарихчылар белән әңгәмәләр китерелә. Алар сәфәр урынын тагын да ныграк ачып бирә. Бер үк урынга ике төрле караш: беренче тапкыр килгән туристныкы һәм шушы җирдә гомер итүчеләрнеке. Әлеге синхроннар динамикага да ирешергә булыша, тапшыруны мәгълүмати яктан баета.

Юлчы» тапшыруы трэвел-журналистиканың документальлеккә омтылган камил үрнәкләреннән берсе. Моңарчы, Халкым минем», Татарлар» тапшырулары теге яки бу төбәктә яшәүче милләттәшләрне күп төшерде, сәяхәт итте. Ләкин аларның төп максаты – сәфәргә чыгу түгел иде, үзәгендә сәяхәт итү темасы булмады. Максатчан рәвештә, трэвел-журналистика тапшырулары моңарчы төшерелмәде. Юлчы» үзәк каналларда күрсәтелүче тапшырулардан калышмый, мәгълүматның тирәнлеге белән өстен тора дияргә мөмкин.

## Әдәбият:

1. Кузнецов Г.В., Цвик В.Л., Юровский А.Я. Телевизионная журналистика: учебник, 4-е издание. М.: Изд-во. МГУ, изд-во «Высшая школа», 2008. 304 с.
2. Лучинская С. Ю. Журналы-травелоги на российском медийном рынке // Вестн. Адыгейского гос. ун-та. 2008. Вып. 3 (31). 200 с.
3. Редькина Т. Ю. Этические и речевые нормы в трэвел-медиатексте: Экология языка и коммуникативная практика. СПб. №1. 2014. 301 с.

Ростовская Ю. В. Журналы путешествий. История развития специализированной периодики в России // Вопросы теории и практики журналистики, 2015. № 2. 328 с.

4. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 29 сент., 15 сәг. 30 мин.
5. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 3 ноябрь, 15 сәг. 30 мин.
6. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 2 декабрь, 15 сәг. 30 мин.

**Ф.Р. Сибгаева**
доцент
Казанский (Приволжский) федеральный университет
*г. Казань, Россия*
© Ф.Р. Сибгаева

## БАСМА МАТБУГАТТА ТӘЭСИР ИТҮ ФУНКЦИЯСЕН БЕЛДЕРҮДӘ ТОТРЫКЛЫ ГЫЙБАРӘЛӘРНЕҢ РОЛЕ

*Аннотация. Известно, что фразеологические единицы, также как и отдельные слова, по употреблению могут быть нейтральными и стилистически маркированными. Практика употребления языка в разных сферах общения людей выработала определенный набор языковых средств в соответствии с задачами каждого стиля. В языке средств массовой информации находит свое воплощение публицистический стиль. Для того чтобы воздействовать на массовое сознание, необходимы наиболее сильные и яркие языковые средства. Именно одним из таких средств можно считать фразеологические обороты. Фразеологизмы рассматриваются не как особая подсистема внутри словарного состава языка, а как набор специфических лексических единиц, органически связанных со всей системой лексики, включенных в общую сеть системных семантических связей ее единиц. Специфика фразеологизмов заключена в их форме, а не в особенностях положения в общей системе лексики. Место это определяется семантической значимостью отдельных фразеологизмов, семантическими связями с другими единицами.*

*Ключевые слова: фразеологическая единица, текст, специфическая лексика, язык средств массовой информации, публицистический стиль.*

*Abstract. It is known that phraseological units, as well as individual words, can be neutral and stylistically marked in use. The*